8. Югары квалификацияле спортчылар әзерләгәндә спортның аерым төрләрендә (шәхси һәм команда составында) спортның арадаш төрләре (акробатика, хореография һ.б.) буенча җәлеп ителә торган тренер-укытучыларга, яулаган урыннарына карап, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларның, спорт буенча тренерларның (спорт буенча өлкән тренер-укытучыларның) хезмәт өчен түләү нормативлары спорт буенча төп тренер-укытучыларга (өлкән тренер-укытучыларга) каралган шартларда спортчыларның әлеге Нигезләмәнең 2 һәм 5 таблицаларында билгеләнгән атналык укыту-тренировка эш режимыннан эшләгән вакытка пропорциональ күләмдә билгеләнә.

9. Яулаган урыннарына карап, рәсми халыкара, бөтероссия, округ һәм республика ярышларында ирешелгән нәтиҗәләре өчен спортчы-инструкторларның һәм спортчыларның хезмәтенә түләү нормативы күләме ярышлар беркетмәсеннән өземтә нигезендә, спортчы-инструкторларның һәм спортчыларның бер календарь ел дәвамында күрсәтелгән нәтиҗәләре вакытыннан алып билгеләнә.

10. Яулаган урыннарына карап, рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында ирешелгән нәтиҗәләре өчен спортчы-инструкторларның һәм спортчының хезмәт өчен түләү нормативы бер календарь елына билгеләнә.

11. Яулаган урыннарына карап, рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында ирешелгән нәтиҗәләре өчен спортчы-инструкторларның һәм спортчыларның хезмәтенә түләү нормативы һәр дәрәҗәдәге ярышлардагы спортчы-инструктор, спортчы (спортчы-инструкторның, спортчының иң күбе сигез ярышы) шәхси зачетта программа рәвешендә, күп төр ярышта яки команда ярышларында (әгәр дә аларда медальләр комплекты уйтанылса) күрсәткән иң яхшы бер нәтиҗә өчен процентлар суммасыннан чыгып билгеләнә.

12. Россия Федерациясе Спорт Министрлыгының бердәм календарь планына кертелгән, аның буенча ярышларда уңышлы чыгыш ясаган тренерларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен акча түләнә торган бөтенроссия ярышлары исемлеге Татарстан Республикасы спорт министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

## V. Спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләрнең вазифаи окладларын формалаштыру тәртибе

1. Спорт резервын әзерләү оешмаларының адаптив физик культура буенча тренерларының, тренер-укытучыларының (шул исәптән өлкән) вазифаи оклады түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$O_d = \left( O_b \times \sum_{i=1}^{n} N_i \right) \times K,$$

биредә:

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмаларының адаптив физик культура буенча тренерларының, тренер-укытучыларының (шул исәптән өлкән) оклады;

$O_b$ - физик культура хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп оклады күләме;

$N_i$ - спорт төрләре буенча спорт әзерлеге этапларында бер шөгыльләнүче өчен адаптив физик культура буенча тренерларның, тренер-укытучыларның (шул исәптән өлкән) хезмәтенә түләү нормативлары;

K - күрсәтелә торган хезмәтләрнең факттагы санын спорт-сәламәтләндерү этабында һәм башлангыч әзерлек этабында норматив күрсәткечкә кадәр җиткерүне тәэмин итә торган кучеш чорына компенсация коэффициенты;

n - укучылар саны.

2. Спорт резервын әзерләү оешмаларының адаптив физик культура буенча тренерларының, тренер-укытучыларның (шул исәптән өлкән) яулаган урынга карап, югары квалификацияле спортчылар әзерләгәне өчен оклады түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$O_v = O_b \times \sum_{i=1}^{n} N_{v_i},$$

биредә:

$O_v$ - спорт резервын әзерләү оешмаларының адаптив физик культура буенча тренерларның, тренер-укытучыларның (шул исәптән өлкән) яулаган урынына карап югары квалификацияле спортчылар әзерләгәне өчен оклады;

$O_b$ - физик культура хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп оклады күләме;

$N_{v_i}$ - яулаган урынына карап, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен адаптив физик культура буенча тренерларның (шул исәптән өлкән), тренер-укытучыларның хезмәтенә түләү нормативлары;

n – укучылар саны.

3. Спорт резервы әзерләү оешмаларының мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең, медицина хезмәткәрләренең, физик культура хезмәткәрләренең (окладлары әлеге Нигезләмәнең 1 бүлегендәге 1 һәм 2 пунктларында билгеләнгән хезмәткәрләрдән тыш), авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең вазифаи оклады түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$

биредә:

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$O_b$ - хезмәткәрләрнең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган төп окладı күләме;

S - ставкаларның факттагы саны.

## VI. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

1. Стимуллаштыру характерендагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы хезмәт нәтиҗәсенә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

1.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр үз эченә түбәндәгеләрне ала:

квалификация категориясе өчен түләүләр;

эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен түләүләр;

югары эш нәтиҗәләре өчен түләүләр;

югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин иткән өчен түләүләр;

спорт дәрәҗәләре, спорт разрядлары өчен түләүләр;

дәүләт бүләкләренә ия булган түләүләр;

профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;

хезмәт нәтиҗәлелеге өчен түләүләр;

премиаль һәм башка кызыксындыру түләүләре;

башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр.

2. Спорт резервын әзерләү оешмаларындагы мәгариф хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгеләү күләме һәм тәртибе.

2.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр педагогик хезмәткәрләрнең һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һөнәри квалификация буенча вазифаи төркемнәре хезмәткәрләренә, квалификация категориясенең гамәлдә булу вакыты югарыләрендә аларның гамәлдәге квалификация категориясе булгандабирелә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

биредә:

$B_{kk}$ - квалификация категориясе өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{kk}$ –квалификация категориясе өчен өстәмә күләме 8 нче таблицада китерелгән.

8 нче таблица

**Мәгариф хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категория | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 11,0 |
| | югары квалификация категориясе | 13,0 |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 11,0 |

| | | |
|---|---|---|
| | югары квалификация категориясе | 13,0 |
| Өченче | беренче квалификация категориясе | 12,0 |
| | югары квалификация категориясе | 15,5 |
| Дүртенче | беренче квалификация категориясе | 13,0 |
| | югары квалификация категориясе | 18,0 |
| Структур бүлекчәләрдәге җитәкче вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 13,0 |
| | югары квалификация категориясе | 18,0 |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 13,0 |
| | югары квалификация категориясе | 18,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән башкарыла.

2.2. Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы союздаш һәм автоном республикаларның һәм Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәгариф хезмәткәрләре вазифалары буенча бирелә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

биредә:

$B_{pz}$ - дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү;

$O_d$ - спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{pz}$ - дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы союздаш республикаларның дәүләт бүләкләре булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Татарстан Республикасы (Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы) дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикалар Союзының, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы союздаш республикаларның тармак бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 4 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең Мактау грамотасына ия булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процент тәшкил итә. Россия Федерациясенең Мактау грамотасына ия булган өчен өстәмә түләү Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының) ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министры (Россия Федерациясе мәгариф министры) боерыгы белән бүләкләнүче мәгариф хезмәткәрләренә билгеләнә.

Татарстан Республикасының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесенә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 2 процентны тәшкил итә. Татарстан Республикасының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесенә ия булган өчен өстәмә түләү Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.

Мәгариф хезмәткәрләренә тиешле түләүләр түләнә торган дәүләт һәм ведомство бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасындагы 1 нче таблицада китерелгән.

2.3. Дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләүләр күләме дәүләт бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләгенә ия булган мәгариф хезмәткәрләренә алар өчен түләү мәгариф хезмәткәренең сайлавы буенча дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

2.4. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр, профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә, төркемнәрдән, һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләреннән чыгып, стаж буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

биредә:

$B_s$ -профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_s$ - профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме 9 нчы таблицада китерелгән

9 нчы таблица

**Профиль буенча эш стажына өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж төркеме | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифалары | беренче - дүртенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 3,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 4,5 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 5,5 |
| | | 15 елдан артык | 6,5 |
| Структура бүлекчәләренең җитәкче вазифалары | беренче - икенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 3,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 4,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 5,5 |
| | | 15 елдан артык | 6,5 |

2.5. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмен билгеләү (үзгәртү), стажны раслаган документлар учреждениедә булган очракта, эш стажы өчен түләүләр күләмен арттырырга хокук бирә торган стаж тулган көннән алып яки стажны раслаган кирәкле документны тапшырган көннән башкарыла.

3. Спорт резервын әзерләү оешмалары мәдәният хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгеләү күләме һәм тәртибе.

3.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр, һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, тариф-квалификация характеристикалары нигезендә аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләре бирүне күз алдында тота торган белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

монда:

$B_{kk}$ -квалификация категориясе өчен түләү;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{kk}$ - квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме 10 нчы таблицада китерелгән

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) боерыгындагы дата нигезендә башкарыла.

10 нчы таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме**

| Квалификация категориясе | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең | |

| әйдәп баручы буын вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
|---|---|
| Беренче квалификация категориясе | 5,0 |
| Югары квалификация категориясе | 8,0 |

3.2. Дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләүләр мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

биредә:

$B_{pz}$ -дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

Dpz - дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләүләр күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалары Союзы составында автоном республикаларының дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренә тиешле түләүләр түләнә торган дәүләт бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасындагы 2 нче таблицада китерелгән.

3.3. Дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү күләме, аларны биргән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләкләре булган хезмәткәрләргә түләү хезмәткәр сайлау буенча дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

3.4. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр, хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларының үтәлешен исәпкә алып, профиль буенча эш дәвамлылыгына карап, һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып стажга карап төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

биредә:

$B_s$ -профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи окладу;

$D_s$ - профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме 11 нче таблицада китерелгән

11 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Стаж төркеме | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының урта буын һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 1,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,0 |
| | 15 елдан артык | 2,5 |
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының әйдәп баручы буын һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,0 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 2,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 3,5 |
| | 15 елдан артык | 4,0 |

3.5. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар учреждениедә булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкән көннән алып, яисә стажны раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

4. Спорт резервын әзерләү оешмаларының медицина хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгеләү күләмнәре һәм тәртибе.

4.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр, һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, аттестация йомгаклары буенча тариф-квалификация характеристикалары нигезендә квалификация категорияләре бирүне күз алдында тота торган белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә.Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

биредә:

$B_{kk}$ -квалификация категориясе өчен түләү;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{kk}$ - квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме 12 нче таблицада китерелгән

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

12 нче таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме.**

| Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 3,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 6,0 |
| Югары квалификация категориясе | 10,0 |
| Табиблар һәм провизор персоналы вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 6,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| Югары квалификация категориясе | 20,0 |

4.2. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр аерым учреждениеләрдәге медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd},$$

биредә:

$B_{sd}$ - эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{sd}$ - эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен 16,2 процентка тигез итеп кабул ителә торган өстәмә күләме;

4.3. Әлеге оешмада, бүлекчәдә һәм вазифада конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр билгеләнә торган хезмәткәрләрнең вазифалар исемлеге сайлап куелган профсоюз органы яисә хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләте булган бүтән орган белән килешенеп, һәр учреждение тарафыннан раслана.

4.4. Дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

биредә:

$B_{pz}$ -дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{pz}$ - дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы автоном республикаларның дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган дәүләт бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасындагы 3 нче таблицада китерелгән.

4.5. Дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү күләме дәүләт бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләкләренә ия булган хезмәткәрләргә түләү хезмәткәрнең сайлавы буенча, дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

4.6. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр, профиль буенча эш дәвамлылыгына карап, һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, стажгакарап төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_s = O_d \times D_{sr},$$

биредә:

$B_s$ -профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{sr}$ - профиль буенча стажы өчен өстәмә түләү күләме 13 нче таблицада китерелгән

13 нче таблица

**Профиль буенча стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Стаж төркеме | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Урта медицина и фармацевтика персоналы | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга | 3,5 |

| | | |
|---|---|---|
| | кадәр | |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Табиб һәм провизорлар | 3 елдан 5 елга кадәр | 5,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 7,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 9,0 |
| | 15 елдан артык | 10,0 |

4.7. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар учреждениедә булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стаж тулган көннән алып, яисә стажны раслый торган кирәкле документ тапшырылган көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

4.8. Хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр урта медицина һәм фармацевтика персоналы, табиблар һәм провизорлар вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазифалары буенча бирелә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_{sr} = O_d \times D_{sr}$$

биредә:

$B_{sr}$ - хезмәтнең киеренкелеге өчен түләүләр;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{sr}$ - хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләме 14 нче таблицада китерелгән

14 нче таблица

**Хезмәтнең киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләүләр диапазоны, процентларда |
|---|---|---|
| Урта медицина и фармацевтик персонал | икенче | 1,5 |
| | өченче | 3,0 |
| | дүртенче | 4,5 |

| | | |
|---|---|---|
| | бишенче | 10,0 |
| Табиб һәм провизорлар | беренче- икенче | 3,0 |

5. Спорт резервын әзерләү оешмаларының физик культура хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгеләү күләме һәм тәртибе.

5.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр икенче һәм өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләренә гамәлдәге квалификация категориясе булган очракта квалификация категориясенең гамәлдә булу вакыты югарыләрендә бирелә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

биредә:

$B_{kk}$ -квалификация категориясе өчен түләү;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{kk}$ - квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме 15 нче таблицада китерелгән.

15 нче таблица

**Физик культура хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Физик культура хезмәткәрләре вазифаларының икенче дәрәҗә һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 5,0 (11,0 <*>) |
| | югары квалификация категориясе | 6,0 (13,0 <*>) |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 6,0 (11,0 <*>) |
| | югары квалификация категориясе | 8,5 (13,0 <*>) |
| Өченче | беренче квалификация категориясе | 7,5 (12,0 <*>) |
| | югары квалификация категориясе | 10,0 (15,5 <*>) |
| Өченче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләренең вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 8,5 |
| | югары квалификация категориясе | 12,5 |
| -------------------------------- | | |

<*> Физкультура спорт оешмалары тренеры, инструктор-методисты (шул исәптән өлкән)

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән башкарыла.

5.2. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр беренче, икенче һәм өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләренә бирелә һәм хезмәт хакы буенча тарифлар түбәндәге формула нигезендә исәпләнә: вазифаи оклад буенча тарификацияләнә торган хезмәткәрләр өчен:

$$B_{sd} = O_d \times D_{sd} \times \frac{H_{f_{sd}}}{H_n},$$

оклад (хезмәт хакы ставкасы) буенча тарификацияләнә торган хезмәткәрләр өчен:

$$B_{sd} = O_b \times D_{sd} \times \sum_{i=1}^{m} N_i,$$

биредә:

$B_{sd}$ - эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;

$D_{sd}$ махсуслаштырылган олимпия резервының оешмаларында (бүлекчәләрендә) эшчәнлек үзенчәлеге өчен 7 процентка тигез итеп кабул ителә торган өстәмә түләү күләме;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$O_b$ -әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган хезмәткәрләрнең төп оклады күләме;

$H_{f_{sd}}$ - кулланучыларның аерым категорияләре булган спорт резервын әзерләү оешмаларындагы физик культура хезмәткәрләренең эш сәгатьләренең күләме;

$H_n$ - спорт резервы әзерләү оешмаларындагы педагогик хезмәткәрләренең хезмәт хакының төп ставкасы өчен әлеге Нигезләмәнең IV бүлеге белән билгеләнгән сәгать нормасы;

$N_i$ - спорт резервын әзерләү учреждениеләрендә спорт төрләре буенча спорт әзерлеге этапларында тренерларның (шул исәптән өлкән), тренер-укытучыларның хезмәтенә бер шөгыльләнүче өчен түләү нормативлары;

$m$ - кулланучылар белән эшләгән өчен, эшчәнлекнең үзенчәлегенә түләүләр билгеләү каралган әлеге кулланучылар саны.

5.3. Әлеге учреждениедә, бүлекчәдә һәм вазифада конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр билгеләнә торган физик культура хезмәткәрләре вазифалары исемлеге сайлап куела торган профсоюз органы яисә хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләте булган башка орган белән килешенеп, һәр учреждение тарафыннан раслана.

5.4. Ярышларда алган урынга карап, югары эш нәтиҗәләре өчен түләүләр рәсми халыкара,бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында уңышлы чыгышлары һәм ирешкән уңышлары өчен спортчы-инструкторларга, спортчыларга бирелә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_{vrr} = O_d \times D_{vrr},$$

биредә:

$B_{vrr}$ - югары эш нәтиҗәләре өчен түләүләр;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{vrr}$ - югары эш нәтиҗәләре өчен өстәмә түләүләр күләме 16 нчы таблицада китерелгән.

5.5. Ярышларда алган урынга карап, югары эш нәтиҗәләре өчен түләүләр ярышлар беркетмәсеннән өземтә нигезендә, спортчы тарафыннан бер календарь ел дәвамында күрсәтелгән нәтиҗәгә ирешкән вакыттан алып билгеләнә.

5.6. Ярышларда алган урынга карап, югары эш нәтиҗәләре өчен түләүнең гамәлдә булу срогы бер календарь елга билгеләнә.

5.7. рышларда алган урынга карап, югары эш нәтиҗәләре өчен өстәмә түләүләр күләме һәр дәрәҗәдәге ярышларда (спортчының сигез ярышыннан артмаган) программа рәвешендә шәхси зачетта, күптөрле ярышларда спортчы, спортчы-инструктор тарафыннан күрсәтелгән иң яхшы нәтиҗә өчен яисә, әгәр мондый ярышларда медаль комплектлары уйнатылса, команда ярышларындагы нәтиҗә өчен процентлар суммасыннан ясала.

16 нчы таблица

**Югары эш нәтиҗәләре өчен өстәмә түләүләр күләме**

(процентларда)

| Ярышларның дәрәҗәсе | Алынган урын | Өстәмә түләүләр күләме | |
|---|---|---|---|
| | | олимпия спорт төрләре, олимпия дисциплиналары | олимпиядә булмаган спорт төрләре, олимпиядә булмаган дисциплиналар |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Олимпия уеннары | 1 | 500,0 | - |
| | 2 | 375,0 | - |
| | 3 | 250,0 | - |
| | 4 | 200,0 | - |
| | 5 | 187,5 | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 6 | 125,0 | - |
| | катнашу | 62,5 | - |
| Дөнья чемпионаты | 1 | 150,0 | 105,0 |
| | 2 | 140,0 | 100,0 |
| | 3 | 130,0 | 95,0 |
| | 4 | 120,0 | 90,0 |
| | 5 | 110,0 | 85,0 |
| | 6 | 100,0 | 70,0 |
| Дөнья кубогы, Европа чемпионаты | 1 | 140,0 | 100,0 |
| | 2 | 130,0 | 90,0 |
| | 3 | 120,0 | 85,0 |
| | 4 | 110,0 | 75,0 |
| | 5 | 100,0 | 70,0 |
| | 6 | 90,0 | 65,0 |
| Европа Кубогы, дөнья беренчелеге | 1 | 120,0 | 85,0 |
| | 2 | 110,0 | 75,0 |
| | 3 | 100,0 | 70,0 |
| | 4 | 90,0 | 65,0 |
| Бөтендөнья универсиадасы | 1 | 120,0 | 85,0 |
| | 2 | 110,0 | 75,0 |
| | 3 | 100,0 | 70,0 |
| | 4 | 90,0 | 65,0 |
| Россия чемпионаты, Европа беренчелеге | 1 | 100,0 | 70,0 |
| | 2 | 90,0 | 65,0 |
| | 3 | 80,0 | 55,0 |
| | 4 | 70,0 | 50,0 |
| Россия кубогы, Россия беренчелеге | 1 | 80,0 | 55,0 |
| | 2 | 70,0 | 45,0 |
| | 3 | 60,0 | 40,0 |
| | 4 | 50,0 | 35,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Бөтенроссия универсиадасы | 1 | 35,0 | 17,5 |
| | 2 | 30,0 | 15,0 |
| | 3 | 25,0 | 12,5 |
| | 4 | 20,0 | 10,0 |

5.8. Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин итү өчен түләүләр, хезмәткәр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларын үтәүне исәпкә алып, спортчыларның уңышлы чыгышлары һәм рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында ирешкән нәтиҗәләре
өчен физик культура хезмәткәрләре вазифаларының беренче дәрәҗә һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә һәм физик культура хезмәткәрләре вазифаларының икенче дәрәҗә һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә (спортчы-инструкторлардан, спортчылардан кала) бирелә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_{vytp} = O_d \times D_{vytp}$$

биредә:

$B_{vytp}$ - югары сыйфатлы укыту- тренировка процессын тәэмин иткән өчен түләү;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{vytp}$ - югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин иткән өчен өстәмә түләү күләме 17 нче таблицада китерелгән;

5.9. Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин итү өчен түләүләр спортчы тарафыннан бер календарь ел дәвамында күрсәткән нәтиҗәгә ирешкән вакыттан алып, ярышлар беркетмәсеннән алынган өземтә нигезендә билгеләнә.

5.10. Югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин итү өчен түләүнең гамәлдә булу срогы бер календарь елга билгеләнә.

5.11. Спортчы-инструктор, спортчыларга югары сыйфатлы укыту-тренировка процессын тәэмин иткән өчен хезмәт хакы түләү нормалары спортчы-инструктор, спортчының программа рәвешендәге шәхси зачетта күптөрле ярышларда (спортчының ярышлары сигездән дә артмаганда) күрсәткән яки медальләр комплекты уйнатыла торган команда ярышларында күрсәткән иң яхшы нәтиҗә өчен процентлар суммасыннан билгеләнә.

17 нче таблица

**Педагогик хезмәткәрләр вазифаларына югары сыйфатлы укыту-тренировкалар процессын тәэмин иткән өчен өстәмә түләү күләме**

(процентларда)

| Квалификация дәрәҗәсе | Ярышлар дәрәҗәсе | Яуланган урын | Өстәмә түләү күләме | |
|---|---|---|---|---|
| | | | олимпия спорт төрләре, | олимпия булмаган спорт |

| | | | олимпия дисциплинала ры | төрләре, олимпия булмаган дисциплиналар |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфалары | | | | |
| Беренче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 2,5 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 2,5 | 1,5 |
| | дөнья Кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 1,5 | 1,0 |
| | Европа Кубогы | 1 - 4 | 1,5 | 1,5 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 1,5 | 1,0 |
| | Россия Кубогы | 1 - 4 | 1,5 | 1,0 |
| | дөнья, Европа беренчелеге | 1 - 6 | 1,5 | 1,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 1,5 | 1,0 |
| | яшьләр, укучылар Спартакиадасы, спорт мәктәпләре арасында Бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 1,0 | 1,0 |
| Икенче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 3,0 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 3,0 | 2,5 |
| | дөнья Кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 2,5 | 2,0 |
| | Европа Кубогы | 1 - 4 | 2,5 | 2,0 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 2,0 | 1,5 |
| | Россия Кубогы | 1 - 4 | 2,0 | 1,5 |
| | дөнья, Европа беренчелеге | 1-6 | 2,5 | 2,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 1,5 | 1,5 |
| | яшьләр, укучылар Спартакиадасы, спорт мәктәпләре арасында Бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 3 | 3 |
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифалары | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Беренче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 3,5 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 3,5 | 3,0 |
| | дөнья Кубогы, Европа чемпионаты | 1-6 | 3,0 | 2,5 |
| | Европа Кубогы | 1 - 4 | 3,0 | 2,5 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 2,5 | 1,5 |
| | Россия Кубогы | 1 - 4 | 2,5 | 1,5 |
| | дөнья, Европа беренчелеге | 1 - 6 | 2,5 | 2,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 2,5 | 2,0 |
| | яшьләр, укучылар Спартакиадасы, спорт мәктәпләре арасында Бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 2,0 | 2,0 |
| Икенче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 4,0 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 4,0 | 3,5 |
| | дөнья Кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 3,5 | 3,0 |
| | Европа Кубогы | 1 - 4 | 3,5 | 3,0 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 3,0 | 2,5 |
| | Россия Кубогы | 1 - 4 | 3,0 | 2,5 |
| | дөнья, Европа беренчелеге | 1 - 6 | 3,5 | 3,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 2,5 | 2,5 |
| | яшьләр, укучылар Спартакиадасы, спорт мәктәпләре арасында Бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 2,0 | 2,0 |
| Өченче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 5,0 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 5,0 | 4,0 |
| | дөнья Кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 4,0 | 3,5 |
| | Европа Кубогы | 1 - 4 | 4,0 | 3,5 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 3,5 | 3,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Россия Кубогы | 1 - 4 | 3,5 | 3,0 |
| | дөнья, Европа беренчелеге | 1 - 6 | 3,5 | 3,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 3,0 | 3,0 |
| | яшьләр, укучылар Спартакиадасы, спорт мәктәпләре арасында Бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 2,5 | 2,5 |
| Өченче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифалары | | | | |
| Беренче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 6,0 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 6,0 | 5,0 |
| | дөнья Кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 5,0 | 4,5 |
| | Европа Кубогы | 1 - 4 | 5,0 | 4,5 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 4,0 | 4,0 |
| | Россия Кубогы | 1 - 4 | 4,0 | 4,0 |
| | дөнья, Европа беренчелеге | 1 - 6 | 4,5 | 4,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 4,0 | 4,0 |
| | яшьләр, укучылар Спартакиадасы, спорт мәктәпләре арасында Бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 3,5 | 3,5 |
| Икенче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 7,5 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 7,5 | 6,0 |
| | дөнья Кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 6,0 | 4,0 |
| | Европа Кубогы | 1 - 4 | 6,0 | 5,0 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 5,0 | 4,5 |
| | Россия Кубогы | 1 - 4 | 5,0 | 4,5 |
| | дөнья, Европа беренчелеге | 1 - 6 | 5,5 | 5,5 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 4,5 | 4,5 |
| | яшьләр, укучылар | 1 - 3 | 4,0 | 4,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Спартакиадасы, спорт мәктәпләре арасында Бөтенроссия ярышлары финалы | | | |
| Дүртенче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифалары | | | | |
| Беренче | Олимпия уеннары | 1 - 6 | 12,5 | |
| | дөнья чемпионаты | 1 - 6 | 12,5 | 7,5 |
| | дөнья Кубогы, Европа чемпионаты | 1 - 6 | 7,5 | 6,0 |
| | Европа Кубогы | 1 - 4 | 7,5 | 6,0 |
| | Россия чемпионаты | 1 - 4 | 6,0 | 5,0 |
| | Россия Кубогы | 1 - 4 | 6,0 | 5,0 |
| | дөнья, Европа беренчелеге | 1 - 6 | 7,0 | 7,0 |
| | Россия беренчелеге | 1 - 4 | 6,0 | 6,0 |
| | яшьләр, укучылар Спартакиадасы, спорт мәктәпләре арасында Бөтенроссия ярышлары финалы | 1 - 3 | 5,0 | 5,0 |

5.12. Спорт дәрәҗәләре, спорт разрядлары өчен түләү спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга тиешле спорт дәрәҗәләре һәм спорт разрядлары бирү өчен кирәкле нормаларны һәм таләпләрне үтәгән өчен бирелә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_{szsr} = O_d \times D_{szsr},$$

биредә:

$B_{szsr}$ - спорт дәрәҗәләре, спорт разрядлары өчен түләүләр;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{szsr}$ - спорт дәрәҗәләре, спорт разрядлары өчен өстәмә түләү күләме 18 нче таблицада китерелгән.

5.13. Спорт дәрәҗәләре, спорт разрядлары өчен түләүләр аларны бирү турындагы приказ яки карар датасы белән билгеләнә.

18 нче таблица

**Спорт дәрәҗәләре, спорт разрядлары өчен өстәмә түләүләр күләме**

| N | Спорт дәрәҗәсе (спорт разряды) атамасы | Өстәмә түләүләр |
|---|---|---|

| т/б | | күләме, процентларда |
|---|---|---|
| 1. | Россиянең халыкара класслы спорт мастеры | 27,0 |
| 2. | Россиянең спорт мастеры | 20,0 |
| 3. | Россиянең гроссмейстеры | 20,0 |
| 4. | Спорт мастерлыгына кандидат | 9,0 |

5.14. Дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү физик культура хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

биредә:

$B_{pz}$ - дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{pz}$ - дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республика Союзы составындагы автоном республикаларның дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республика Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның дәүләт бүләкләренә, спорт дәрәҗәләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Физик культура хезмәткәрләренә түләүләр бирелә торган дәүләт бүләкләре, спорт дәрәҗәләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасындагы 4 нче таблицасыда китерелгән.

5.15. Дәүләт бүләкләренә, спорт дәрәҗәләренә ия булган өчен түләү күләмен билгеләү дәүләт бүләге, спорт дәрәҗәсе бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләгенә, ике һәм аннан күбрәк спорт дәрәҗәсенә ия булган хезмәткәрләргә алар өчен түләү хезмәткәр сайлап алган бер бүләк яки дәрәҗә буенча билгеләнә .

5.16. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр, профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә, төркемнәр буенча, һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә стажга карап билгеләнә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

биредә:

$B_s$ -профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи окладты;

$D_s$ - профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме 19 нчы таблицада китерелгән.

19 нчы таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж төркеме | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазифалары (1 нче төркем) | беренче-икенче- | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | | 15 елдан артык | 5,5 |
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары (2 нче төркем) | беренче-өченче- | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 (3,0 <*>) |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 (4,5 <*>) |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 (5,5 <*>) |
| | | 15 елдан артык | 5,5 (6,5 <*>) |
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары (3 нче төркем) | беренче | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | | 15 елдан артык | 5,5 |

--------------------------------

<*> Физкультура спорт оешмалары тренеры, инструктор-методисты (шул исәптән өлкән)

5.17. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар учреждениедә булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажны тутырган көннән алып, яисә стажны раслый торган кирәкле документ бирелгән көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

6. Спорт әзерлеге һәм спорт резервын әзерләү учреждениеләренең авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме һәм аларны билгеләү тәртибе.

6.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр, һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, тарифквалификация характеристикалары нигезендә аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләре бирүне күз алдында тота торган белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times D_{kk},$$

биредә:

$B_{kk}$ -квалификация категориясе өчен түләүләр;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи окладлы;

$D_{kk}$ - квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме 20 нче таблицада итерелгән

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

20 нче таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|
| «Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация категориясе | 5,0 |
| Югары квалификация категориясе | 8,0 |

6.2. Дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times D_{pz},$$

биредә:

$B_{pz}$ -дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләү;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлы;

$D_{pz}$ - дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме.

Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автоном республикаларның дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Союзының, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның дәүләт бүләкләренә ия булган өчен өстәмә түләү күләме 7 процент тәшкил итә.

Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә дәүләт бүләкләренә ия булган өчен түләүләр бирелә торган дәүләт бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәнең кушымтасындагы 5 нче таблицада китерелгән.

6.3. Дәүләт бүләкләре булган өчен түләү күләмен билгеләү дәүләт бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк дәүләт бүләкләренә ия булган хезмәткәрләргә түләү хезмәткәрнең сайлавы буенча дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә.

6.4. Профиль буенча эш стажы өчен түләүләр, хезмәткәрләр эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларын үтәүне исәпкә алып, профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә, авыл хуҗалыгы буенча һөнәри квалификация төркемнәреннән чыгып, стажга карап, төркемнәр буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула нигезендә исәпләнә:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

биредә:

$B_s$ -профиль буенча эш стажы өчен түләү;

$O_d$ -спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_s$ - профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме 21 нче таблицада китерелгән

21 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Стаж төркеме | Өстәмә түләүләр күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 5 елга кадәр | 3,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 4,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 5,5 |
| | 15 елдан артык | 6,5 |

6.5. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләме, әгәр стажны раслый торган документлар учреждениедә булса, профиль буенча эш стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукын бирә торган стажны тутырган көннән алып яисә стажны раслый торган кирәкле документ бирелгән көннән алып билгеләнә (үзгәртелә).

7. Спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренә юбилей даталары, аерым хөрмәт билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алуга бәйле рәвештә һәм оешманың локаль актлар һәм коллектив килешүләре белән билгеләнгән башка нигезләре буенча премия һәм башка стимуллаштыру түләүләре билгеле вакыт өчен (ай, квартал, ел) төп эш урыны буенча бер тапкыр билгеләнә.

7.1. Эш нәтиҗәләре буенча премия һәм башка стимуллаштыру түләүләрен гамәлгә ашыру күләмнәре, тәртибе һәм шартлары оешманың локаль актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнә.

7.2. Спорт резервын әзерләүне оештыру хезмәткәрләренә премия түләүгә каралган хезмәт өчен түләү фонды күләме хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазифасы буенча окладлар (хезмәт хакы ставкалары, вазифаи окладлар), кызыксындыру сыйфатындагы түләүләр башкаруга каралган хезмәт өчен түләү фондының кимендә 2 процентын тәшкил итә.

7.3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 17 октябрендәге 2245-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Россия Федерациясендә спорт резервын әзерләү концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын үтәгәндә спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керә торган хезмәткәрләргә һәм икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри-квалификация төркеменә керә торган хезмәткәрләргә төп эш һәм төп вазыйфа буенча бер тапкыр түләнә торган түләү башкарылырга мөмкин.

